| БАВЛИНСКИЙ ГОРОДСКОЙ СОВЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ |
|---|---|

---

РЕШЕНИЕ                    КАРАР

05.05.2026          Баулы шәһәре          №23

**Баулы шәһәре чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге буенча Татарстан Республикасы «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыруны гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юллары исемлеген, юл-урам челтәрен раслау өлешендә Баулы муниципаль районы җирле үзидарә органнарына тапшыру турында**

«Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы Федераль законның 5 статьясындагы 9 пункты, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 15 статьясындагы 3 өлешенең 17 пункты, «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә, Баулы шәһәр Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнарының Баулы шәһәре чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге буенча вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыруны гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юллары исемлеген, юл-урам челтәрен раслау өлешендә Баулы муниципаль районы җирле үзидарә органнарына тапшырырга.

2. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль район Советына тәкъдим итәргә:

әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрнең бер өлешен кабул итү турындагы мәсьәләне карарга;

«Баулы шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны кабул итү-тапшыру турында Баулы шәһәре чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге буенча Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының җирле үзидарә органнарына гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юллары исемлеген, юл-урам челтәрен раслау өлешендә килешү төзергә.

3. «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны кабул итү-тапшыру турында Баулы муниципаль районы чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге буенча Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнарына гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юллары, юл-урам челтәре исемлеген раслау өлешендә килешү рәсми басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Баулы шәһәре мэры,
шәһәр Советы рәисе                                        И.И. Гозәеров